

Октябрь башында бәйрәмне - Олкәннәр конен билгеләп vтv яхшы традициягә әверелде. Бу кон лаек-лы, акыллы, хормәтле, нык һәм чыдамлы, зур хәреф белән языла торган кешеләргә багышлана. Олкәннәр коне - чиста һәм якты бәйрәм; әти-әниләребез, әби-бабайларыбыз бәй-рәме.
23 октябрьдә Ләмберә районы Черемиш авыл китапханәсендә “Черемиш мәдәният йорты” белән берлектә, “Еллар чигәләргә кол булып куна” (“Годы пеплом оседают на висках”) тематик кичәсе уздырылган. Анда бар авыл халкы катнашкан. Башлангыч сыйныф укучылары һәм сыйныф житәкчесе Винера Асыйм кызы Карабанова шигырьле, жырлы, частушкалы матур концерт номерлары әзерләгәннәр. Авылдашлары - әти-әниләре, әби-бабайлары укучыларнын чыгышларын алкышларга кvмгәннәр, рәхәтләнеп ял иткәннәр. Концерт кvнелләрен жылыткан.
Аннары чарада катнашучылар, vткән елларны искә алып, бер чынаяк хуш исле чәй эчеп, балачак һәм бvгенге кон турында сойләшкәннәр.
Шулай ук vткән атнада Атюрьево, Зубово-Поляна, Рузаевка, Ләмберә (Кривозерье, Татар Тавласы, Пензятка) районнары татар авылларында олыларны хормәт йозеннән, торле-торле чаралар vткәргәннәр.